Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

№ 4 10.03.2015 ел

2015 елга Яңа Ибрай авыл җирлегендә коррупциягә каршы тору чаралары планын раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының «2014-2015 елларга коррупциягә каршы торуның милли планы турында» 2014 елның 11 апрелендәге 226 номерлы Указын үтәү йөзеннән Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРА::

1. Кушымта нигезендә Яңа Ибрай авыл җирлегендә коррупциягә каршы тору чаралары планын расларга.
2. Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына планның үтәлешенә квартал саен мониторинг үткәрергә.
3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:Aksubayevo.tatarstan.ru
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Ибрай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Ф.Х.Кәбиров

Кушымта
Яңа Ибрай авыл җирлеге
Башкарма комитет карарына
10.03.2015 ел № 4

2015 елга Яңа Ибрай авыл җирлегендә коррупциягә каршы тору буенча чаралар планы

| № п/п | Чара исеме | Үтәлү вакыты | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 нче бүлек. Мөнфәгатьләр конфликтын җайга салу механизмнарының нәтиҗәлелеген арттыру, муниципаль хезмәткәрләрнең вазифа бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә хезмәт тәртибе чикләүләрен, тыюларын һәм принципларын үтәүләрен тәэмин итү, шулай ук аларны бозган өчен җаваплылыкка тартуның котылгысызлыгын тәэмин итү. | | | |
| 1 | 1.1.Муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүне оештыру, аларның вазифа бурычларына коррупциягә каршы тору керә. | даими | Җирлек башлыгы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| | 1.2."Яңа Ибрай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тоту | даими | Җирлек башлыгы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 2 | 2.1. Ришвәтчелек куркынычлары белән бәйле вазыйфаларда муниципаль хезмәт үтәүче муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын үтәвен мониторинглау. | даими | Җирлек башлыгы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| | 2.2. Муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны вакытында бирүләрен тикшерү | Ел саен 30 апрельгә кадәр | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| | 2.3. Коррупциягә каршы тору буенча норматив хокукый актларның үтәлешен тикшерү | Квартал саен | Җирлек башлыгы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| | 2.4. Яңа Ибрай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларын муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча федераль һәм республика законнарына туры китерү һәм коррупциягә каршы тору | даими | Җирлек башлыгы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | 3.1.Муниципаль хезмәткәрләрнең 5 нче карары 18 04 2011 ел белән расланган этика һәм хезмәт тәртибе кодексын үтәүләрен тәэмин итү. .<br>3.2. Муниципаль хезмәткәрләрнең ротация механизмын кертү буенча эшне оештыру. | даими | Җирлек башлыгы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 4 | 4.1. Дәүләт серен саклауны тәэмин итү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматларын яклау.<br>4.2. Коррупциягә каршы торуны оештыру мәсьәләләре буенча хокук саклау органнары һәм башка дәүләт органнары белән нәтиҗәле хезмәттәшлекне тәэмин итү | даими | Җирлек башлыгы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| Бүлек.2. Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә җәмәгать контроле механизмнарын булдыру, кире элемтә системасын булдыру | | | |
| 5. | "Аксубай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында муниципаль хезмәткәрләрнең, аларның тормыш иптәшләренең, балигъ булмаган балаларның керемнәре турында мәгълүмат урнаштыру | Ел саен 30 апрельгә кадәр | Җирлек башлыгы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 6 | 7.1. Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләрдә Интернет челтәрендәге тиешле рәсми сайтта җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматның ачык һәм ачык булуын тәэмин итү, коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ММЧ белән үзара хезмәттәшлек итү. | даими | Җирлек башлыгы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 8. | Аксубай муниципаль районы коррупциягә каршы тору комиссиясенең коррупциягә каршы тору чараларын гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүмат бирү | Даими | Җирлек башлыгы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 4 нче бүлек. Яңа Ибрай авыл җирлеге хакимиятенең коррупциялe факторлар булган норматив хокукый актлары санын киметү | | | |
| 9. | 11.1. Яңа Ибрай авыл җирлегенең норматив хокукый актларына планлы | Квартал саен | Җирлек башлыгы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | коррупциягә каршы экспертиза үткәрү<br>11.2 Яңа Ибрай авыл җирлегенең норматив хокукый актлары проектларына агымдагы коррупциягә каршы экспертиза үткәрү | даими | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 5 нче бүлек. Муниципаль заказлар урнаштырганда коррупциягә каршы тору | | | |
| | | | |
| 10 | 10.1."Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренең үтәлешен контрольдә тоту | даими | Контракт идарәчесе<br>Авдеева М. Г. |
| | 10.2.Заказчылар һәм муниципаль заказларны үтәүчеләр тарафыннан коррупция күренешләрен булдырмау максатыннан муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә закон таләпләрен тегәл үтәү | | Контракт идарәчесе<br>Авдеева М. Г. |